**Татарстан Республикасы**
**Нурлат муниципаль районы**
**Яңа Иглай авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**24.12.2024 ел** **№ 102**

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Иглай авыл җирлеге Советының 2024 елның 02 июлендәге 89 номерлы «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты нигезендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Иглай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге Советының 2024 елның 02 июлендәге 89 номерлы «Җирле салым суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 5 һәм 6 пунктчалары, 1 пунктын үз көчләрен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Иглай авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Иглай авыл җирлеге Советының «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2024 елның 02 июлендәге 89 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 16 декабрендәге 99 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://nurlat.tatarstan.ru һәм җирлек территориясендәге мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Яңа Иглай авыл җирлеге
Советы башлыгы
вазыйфаларын башкаручы И.Х. Ханәфиев